
Чыганак : **Шәһри Казан. - 1997. - 1 окт.**



КҮРЕНЕКЛЕ галим, тарихчы, төрки дөнья белгече, этногенез теориясе авторы Лев Николаевич Гумилевның вафатына инде 5 ел. Бүген аңа 85 яшь тулган булыр иде. Шул уңайдан Татарстан Республикасы акчасына Санкт-Петербург каласында тантаналы шартларда аңа мемориаль такта ачыла. Әлеге олпат зат шактый еллар буена шунда яшәгән, эшләгән, газиз әнкәсе шагыйрә Анна Ахматова да шунда иҗат иткән, әтисе Николай Гумилевның шигъри таланты да шунда ачылган.

Бу мемориаль такта - Нева ярындагы калада иленең әлегә Лев Николаевич шәхесе алдында зурлап баш июен дәлилләгән бердән-бер һәйкәл. Тантанада Санкт-Петербург губернаторы В.Яковлев, Ленинград өлкәсе губернаторы В.Густов, шулай ук мәдәният комитеты рәисе В.Яковлев, Санкт-Петербург дәүләт университеты ректоры Л.Вирбицкая, башка рәсми кешеләр катнашыр дип көтелә. Бездән вәкил - Татарстан Президенты каршындагы тышкы элемтәләр департаменты директоры Т.Акулов.

Мемориаль тактаны эшләтү һәм урнаштыруны Татарстан Мәдәният министрлыгы җитәкчелегендә республиканың Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге оештырды. Авторы - яшь, талантлы скульптор Әхнәф Зыякаев һәм Владимир Кашаев.

**Шулай итеп, беренче изге адым ясала. Бу шәхеснең исемен мәңгеләштерү йөзеннән бәлки безгә дә Казаныбыздагы берәр фән үзәген, урамны, мәйданны аның исеме белән атарга, анда да мемориаль такта куярга кирәктер. Ничек уйлыйсыз, зыялылар?**